**I. Укыту предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре.**
**Сыйныф**: 8 “А”
**Укытучы**: Васильева А.В
**Уку планы буенча татар теленнән**: 70 сәг.
**Атнага**: 2 сәг.
**БСҮ -6**
**Диктант -2**
**Изложение -2**
**Сочинение -2**

**Программа түбәндәге документлар нигезендә төзелде:**

1. Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларында “Туган тел (татар теле) укыту предметыныңүрнәк эш программасы (I – XI сыйныфлар)

Төзүчеләр: педагогика фәннәре докторы, КФУ профессоры Ф.Ф. Харисов, педагогика фәннәре докторы, КФУ профессоры Ч.М. Харисова, педагогика фәннәре кандидаты, КФУ доценты Г.Р. Шакирова

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең төп гомуми белем бирү баскычында урта гомуми белем бирү программасы.
3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем мәктәбе”нең 2018-2019 уку елына укыту планы (№____ педсовет протоколы, ____________2018 ел).

**Дәреслек**. 8 сыйныф: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен)/ Г.Ф. Гайнуллина, Ф.Ф. Харисов.- Казан:Татар .кит.нәшр.,2016.

Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының V – IX сыйныф укучыларына ана теленнән белем бирүнең төп максаты – Стандарт таләпләрен тормышка ашыру белән бергә укучыларда *аралашу, лингвистик* һәм *этнокультура* өлкәләренә караган компетенцияләрне булдыру.

Укучыларның телдән һәм язма сөйләм буенча белем, осталыкка ия булу күрсәткечләре: *аралашу универсаль уку гамәлләре* (сөйләм эшчәнлеге төрләрен белү; өлкәннәр һәм иптәшләре белән татарча сөйләшү, фикерне логик эзлеклелектә җиткерү; аралашу вакытында телдән һәм язма сөйләм нормаларын саклау һ.б.), *танып белү универсаль уку гамәлләре* (проблеманы билгеләү; сөйләмне логик эзлеклелектә оештыру; төрле чыганаклардан мәгълүмат эзләп табу; мәгълүматны эшкәртү, системага салу һәм адресатка җиткерү һ.б.), *регулятив универсаль уку гамәлләре* (үзеңнең гамәлеңне алдан

планлаштыру, кирәк булган очракта аны үзгәртү; үз-үзеңне тикшерү; үзеңнең эшчәнлегеңә бәя бирү һ.б.).

## 1. “ТУГАН ТЕЛ (ТАТАР ТЕЛЕ)” УКЫТУДАН КӨТЕЛГӘН ПРЕДМЕТ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларында, татар телен туган тел буларак укытканда, Стандарт нигезендә түбәндәге таләпләр куела:

- укучыларны үз иленең гражданнары һәм патриотлары итеп тәрбияләү, аларны халыкның рухи, әхлакый һәм мәдәни кыйммәтләрен үзләштерердәй итеп үстерү;
- укучыларның рухи-әхлакый сыйфатларын булдыру, аларның гражданлык, иҗтимагый, шәхси үсешен тәэмин итү, яшь буынның иҗади сәләтен үстерү, сәламәтлеген саклау һәм ныгыту юнәлешендә эшләү;
- ана теле буенча белем бирүдә эзлеклелекне тәэмин итү;
- балаларга төп белемне сыйфатлы итеп бирү, аларны җәмгыятьтә үз урынын табардай, төрле милләт вәкилләре арасында үзара дус һәм тату яшәрдәй шәхес итеп тәрбияләү;
- белем һәм тәрбия биргәндә, укучыны кабатланмас аерым бер үзенчәлеккә ия булган шәхес итеп күзаллау;
- ана теле дәресләрендә үзләштергән белем һәм күнекмәләрне укучыларның үз сөйләмнәрендә дөрес һәм тиешенчә куллана белүләренә ирешү, орфоэпик, орфографик һәм пунктуацион яктан грамоталы шәхес итеп тәрбияләү;
- балаларда киләчәктә алачак һөнәрләренә аңлы караш тәрбияләү, аларның җәмгыятьтә үз урыннарын таба белүләренә ирешүдә ана теленең әһәмиятен аңлату;
- укучыларны шәхси, иҗтимагый, гаилә таләпләренә туры килердәй белем һәм күнекмәләр белән коралландыруны күз уңында тоту;
- балаларга белем бирүне бердәй сыйфатлы итеп, шул исәптән физик мөмкинлекләре чикле булганнар да үзләштерердәй итеп оештыру;
- укучылар ала торган белем һәм тәрбиягә бердәй таләпләр белән якын килү, шәхесне киләчәк иҗимагый тормышта үз урынын табардай итеп тәрбияләү;
- уку-укыту эшендә дәрестән тыш формаларны да тиешенчә файдалану;
- төрле клублар, секцияләр, студия һәм түгәрәк эшләре аша укучыларның сәләтен ачыклау, аларга һөнәри юнәлеш алуда ярдәм итү, укуда һәм җәмәгать эшләрендә катнашу аша сәләтле балаларны барлау һәм аларны алга таба үстерү, бу юнәлештә өстәмә белем бирү оешмаларының эшчәнлегенә таяну;
- уку-укыту эшен тиешенчә оештыруда укучылар белән бергә ата-аналар һәм киң җәмәгатьчелек фикерен дә исәпкә алу;
- укучыларда үзләре яши торган төбәккә (авыл, шәһәр, район, бистәгә) карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү, моның өчен ана теле дәресләре белән бергә әдәбият, география, тарих һәм җәмгыять белеме һ.б. дәресләрне дә файдалану.

**Предметны үзләштергәннән соң көтелгән нәтиҗәләр өч төрле юнәлештә билгеләнә: шәхси, метапредмет һәм предмет нәтиҗәләре**.

Стандарт һәм укыту предметының үзенчәлекләре буенча предмет нәтиҗәләре түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

- укыту предметын нәтиҗәле өйрәнү һәм төрле милләтләр арасында формаль һәм формаль булмаган аралашу өчен кирәк булган дәрәҗәдә сөйләм эшчәнлеге төрләрен камилләштерү;
- белем алу процессында шәхеснең акыл һәм иҗади сәләтен үстерүдә телнең мөһим урын алып торуын аңлау;
- ана теленең аралашу-эстетик мөмкинлекләрен файдалану;
- тел турындагы белемне системага салу, лингвистиканың төп төшенчәләрен үзләштерү;
- сүзгә төрле анализ ясау күнекмәләрен булдыру һәм үстерү (фонетик, морфемик, сүз ясалышы, лексик, морфологик, синтаксик);
- ана теленең әдәби нормаларына (орфоэпик, лексик, грамматик, орфографик, пунктуацион) һәм татар теленең сөйләм этикеты нормаларына ия булу, аларны телдән һәм язма сөйләм практикасында куллану тәҗрибәсен булдыру;
- тел һәм гомумкешелек кыйммәтләренә җаваплылык белән карау хисе тәрбияләү.

## 2. “ТУГАН ТЕЛ (ТАТАР ТЕЛЕ)” УКЫТУ ПРЕДМЕТЫНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

V – IX сыйныфлар программасы укучыларда аралашу, лингвистик һәм этнокультура өлкәләренә караган компетенцияләрне формалаштыруны һәм үстерүне күзаллый.

### *Аралашу компетенциясен булдыру һәм үстерү*

Аралашу компетенциясе ул – башкалар әйткәнне аңлау һәм үз фикереңне белдерү өчен тупланган белем, осталык, күнекмәләр җыелмасы; хәзерге татар әдәби теле нормаларына ия булу, сүз байлыгын, сөйләмнең грамматик ягын дөрес итеп үзләштерү; телдән һәм язма формада бәйләнешле сөйләм күнекмәләре булдыру.

### Сөйләм. Аралашу

Ана телендә иркен итеп сөйләшә һәм аралаша белү – мәдәниятлылыкның мөһим өлеше.

Төрләре буенча сөйләм телдән һәм язма формада, диалогик һәм монологик сөйләм, турыдан-туры, турыдан-туры булмаган формаларда була.

Кулланылу өлкәсе буенча сөйләм көнкүреш өлкәсенә, иҗтимагый-мәдәни, фәнни (фәнни-укыту), иҗтимагый-сәяси, рәсми-эшлекле аралашу даирәләренә карый.

Сөйләм ситуациясе һәм аның төп берәмлекләре буенча катнашучылар өчен (адресант һәм адресат), алдан әзерләнеп һәм әзерләнмичә, рәсми һәм рәсми булмаган формаларда була.

Аралашу шартлары: дөрес (уңышлы) аралашу, уңышсыз аралашуның сәбәпләре һәм аны булдырмау юллары ачыклана.

**Сөйләм эшчәнлеге**

Эшчәнлек буларак сөйләм. Сөйләм эшчәнлеге төрләре: ишетеп аңлау, сөйләү, уку һәм язу.

У к у

Уку шәхеснең аралашу-иҗтимагый эшчәнлегенә карый. Китап белән эшләү культурасы. Уку төрләренә ия булу: эчтән һәм кычкырып уку, тәрҗемә итеп һәм тәрҗемәсез уку, әзерлекле һәм әзерлексез уку, дәрестә һәм өйдә уку. Дәреслек һәм башка чыганаклар белән эшләү алымнары (массакүләм мәгълүмат чаралары, Интернет).

И ш е т е п а ң л а у

Ишетеп аңлау (аудирование) икенче төрле итеп әйткәндә, сөйләмне тыңлап аңлау. Аның өч этабы бар: фрагментар, эчтәлекне һәм мәгънәне аңлау. Зур булмаган (300 сүзгә якын) әдәби, публицистик, укыту-фәнни, фәнни-популяр эчтәлектәге текстларны тыңлап аңлау.

С ө й л ә ү

Сөйләү – эчке сөйләмнең тышкы сөйләмгә күчермәсе. Иҗтимагый-мәдәни, әхлакый-эстетик, иҗтимагый-көнкүреш, укыту һәм башка темалар турындагы сөйләмне аңлау. Диалогта катнашу.

Я з у

Ишеткән һәм язган текстның эчтәлеген язма формада тулы, кыскача, аннотация яки тезис формасында хәбәр итә белү. Язу – аралашу һәм тикшерү чарасы. Язмача, контроль биремнәр ярдәмендә тел материалын үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү. Язма формадагы күнегүләр: рецептив һәм продуктив, тел материалын активлаштыру. Иҗтимагый-мәдәни, әхлакый-эстетик, иҗтимагый-көнкүреш, уку-укытуга караган темаларга үз фикерләреңне язу. Сочинениеләр һәм изложениеләр язу.

Т е к с т

Аның мәгънәви һәм композицион бөтенлеге. Текстның төп фикере – тема. Текстка анализ ясау.

Т е л н е ң ф у н к ц и о н а л ь т ө р л ә р е

Сөйләмә тел, функциональ стильләр һәм аларның жанрлары.

С ө й л ә м к у л ь т у р а с ы

Сөйләм культурасы турында төшенчә һәм аның төп өлешләре.

**VIII сыйныф**

Укыган әдәби әсәр героена адресланган хат язу.

Тормышта үрнәк булырдай берәр кеше турында очерк язу.

Концертка яки театрга баргач алган тәэсирләр турында сөйләшү, диалогик һәм монологик сөйләм үрнәкләрен табу.

Татар һәм рус телләрендәге гади җөмләләрне төзелешләре ягыннан чагыштыру.

Әдәби геройларга телдән яки язмача характеристика бирү.

Татар телендәге сүз тәртибе үзенчәлекләре булган кыска текстларны тәрҗемә итү.

Экологик темага сочинение элементлары булган изложениеләр язу.

Үтелгән темалар кергән грамматик биремле диктантлар язу.

Сыйныфтан тыш укылган әдәби әсәрләргә таянып, сочинениеләр язу.

**Синтаксис.**

Җөмләнең баш кисәкләре. Аларның исемнәр һәм зат алмашлыклары белән белдерелүе (кабатлау).

Җөмләнең иярчен кисәкләреннән аергыч һәм тәмамлык, аларның төрле сүз төркемнәре белән белдерелүе (кабатлау).

Хәл һәм аның төрләре. Хәлләрнең аерымлануы һәм алар янында тыныш билгеләре

Татар телендә җөмлә кисәкләренең урнашу тәртибе, аның рус телендәге сүзләрнең урнашу тәртибеннән аермалы яклары.

Гади җөмлә турында башлангычта үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү.

Әйтү максаты буенча җөмлә төрләре. Хикәя җөмлә, сорау җөмлә, боеру җөмлә һәм тойгылы җөмләләр (кабатлау) һәм алар янында куела торган тыныш билгеләре.

Ике составлы һәм бер составлы җөмләләр. Җыйнак һәм җәенке җөмләләр.

Эндәш сүз һәм кереш сүзләр. Аларның үзенчәлекләре һәм җөмләдәге урыны. Эндәш һәм кереш сүзләр янында тыныш билгеләре.

Раслау һәм инкяр җөмләләр, аларның сөйләмдә кулланылышы.

**Сөйләм үстерү.**

**VIII сыйныф укучыларының белем, осталык һәм күнекмәләренә таләпләр:**

- телдән һәм язма сөйләмдә өйрәнгән синтаксик берәмлекләрне урынлы куллану;
- укыган әсәрнең эчтәлеген сөйләгәндә яки караган спектакль турында фикер алышканда, җөмлә кисәкләренең урнашу тәртибен саклау, үз фикереңне яки мөнәсәбәтеңне туган телдә мөстәкыйль рәвештә белдерү;
- гади җөмләләрнең төрле формаларын кулланып, дәрестә өйрәнелә торган тема турында сөйләү, аларга караган мисаллар әйтү (язу);
- гади җөмләләргә синтаксик анализ ясаганда, телдән һәм язмача аңлату, җөмлә кисәкләрен шартлы билгеләр белән күрсәтү.

## III.Төп уку эшчәнлеге төрләре күрсәтелгән тематик планлаштыру.

| | **Өйрәнелә торган бүлек, уку материалының темасы** | **Уку эшчәнлеге төрләре** | **Үткәрү вакыты** | |
|---|---|---|---|---|
| | | | **Планлаштырылган** | **Факт буенча** |
| 1. | 5-7 нче сыйныфларда үткәннәрне кабатлау | Сүз ясалышы, сүз төзелеше, сүз төркемнәре, җөмләдә сүзләр тәртибен кабатлау, тәрҗемә күнегүләре эшләү. | 3.09 | |
| 2. | 5-7 нче сыйныфларда үткәннәрне кабатлау | Сүз ясалышы, сүз төзелеше, сүз төркемнәре, җөмләдә сүзләр тәртибен кабатлау, тәрҗемә күнегүләре эшләү. | 6.09 | |
| 3. | Сүзләргә фонетик, лексик, морфологик анализлар ясауны кабатлау | Сүзләргә фонетик, лексик, морфологик анализлар ясау тәртибен кабатлау. | 10.09 | |
| 4. | Җөмләнең баш кисәкләре. Ия һәм хәбәр. | Ия, хәбәр турында мәгълүмат бирү | 13.09 | |
| 5. | Кереш контроль эш | Кереш контроль эш | 17.09 | |
| 6. | Бсү. Туган тел турында әңгәмә. | Тел һәм туган тел төшенчәләре Тел гыйлеме , аның тармаклары. Бирелгән тема буенча 8 -10 җөмләдән торган хикәя язу. | 20.09 | |
| 7. | Җөмләнең баш кисәкләре. Ия һәм хәбәр. | Ия, хәбәр турында мәгълүмат бирү.Китап белән эш, тыңлау, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү | 24.09 | |
| 8. | Ия белән хәбәрнең җөмләдәге уыны | Гади хәбәр турында мәгълүмат бирү. Китап белән эш, тыңлау, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү . | 27.09 | |
| 9. | Ия белән хәбәрнең җөмләдә кулланышы. | Гади хәбәр турында мәгълүмат бирү. Китап белән эш, тыңлау, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү . | 1.10 | |
| 10. | Ия белән хәбәр арасына сызык кую очраклары | Җөмләнең хәбәре баш килештәге исем яки исем урынына килгән башка сүз төркеме белән белдерелгәндә, ия белән хәбәр арасына сызык куелу.Укытучы аңлатуы, китап белән эш, тыңлау, күмәк | 4.10 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү | | |
| 11. | Тест биремнәрен үтәү | Тест эшләү | 8.10 | |
| 12. | Җөмләнең иярчен кисәкләре | Җөмләнең иярчен кисәкләрен кабатлап, биремнәр эшләү | 11.10 | |
| 13. | Аергыч | Аергыч турында мәгълүмат бирү.Китап белән эш, тыңлау, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү | 15.10 | |
| 14. | Аергыч белән аерлмыш арасында бәйләнеш | Аергыч белән аерлмыш арасында бәйләнешне аңлату. Карточкалар буенча эшләү | 18.10 | |
| 15. | Тиңдәш һәм тиңдәш булмаган аергычлар | Тиңдәш һәм тиңдәш булмаган аергычлар турында мәгълүмат бирү.Китап белән эш, тыңлау, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү | 22.10 | |
| 16. | **Диктант** | Диктант | 25.10 | |
| 17. | Хаталар өстендә эш | Хаталар өстендә эш | 29.10 | |
| 18. | Тәмамлык | Тәмамлык турында мәгълүмат бирү.Китап белән эш, тыңлау, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү | 8.11 | |
| 19. | Туры һәм кыек тәмамлыклар | Туры һәм кыек тәмамлыклар турында мәгълүмат бирү.Китап белән эш | 12.11 | |
| 20. | Хәл һәм аның төрләре | Хәл һәм аның фигыль белән белдерелүе. Урын хәле белән таныштыру Укытучы аңлатуы, китап белән эш, тыңлау, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү | 15.11 | |
| 21. | Урын хәле | Хәл һәм аның фигыль белән белдерелүе. Урын хәле белән таныштыру Укытучы аңлатуы, китап белән эш, тыңлау, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү | 19.11 | |
| 22. | Урын хәле | Хәл һәм аның фигыль белән белдерелүе. Урын хәле белән таныштыру Укытучы аңлатуы, | 22.11 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | китап белән эш, тыңлау, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү | | |
| 23. | Вакыт хәле | Вакыт хәле һәм аның вакыт рәвеше, хәл фигылнең 3,4 төре, урын-вакыт килешендәге яки бәйлек белән килгән исем һәм башка сүз төркемнәре ярдәмендә белдерелүе.Китап белән эш, тыңлау, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү | 26.11 | |
| 24. | Вакыт хәле | Вакыт хәле һәм аның вакыт рәвеше, хәл фигылнең 3,4 төре, урын-вакыт килешендәге яки бәйлек белән килгән исем һәм башка сүз төркемнәре ярдәмендә белдерелүе.Китап белән эш, тыңлау, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү | 29.11 | |
| 25. | Рәвеш хәле | Рәвеш хәлләренең рәвеш һәм сыйфат белән белдерелүен өйрәнү.Укытучы аңлатуы, китап белән эш, тыңлау, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү | 3.12 | |
| 26. | Күләм хәле | Күләм хәле һәм аның белдерелүе. Укытучы аңлатуы, китап белән эш, тыңлау, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү | 6.12 | |
| 27. | Күләм хәле. Күнегүләр эшләү. | Күләм хәле һәм аның белдерелүе. Укытучы аңлатуы, китап белән эш, тыңлау, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү | 10.12 | |
| 28. | Сәбәп хәле | Сәбәп хәле һәм аның белдерелүе.Укытучы аңлатуы, китап белән эш, тыңлау, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү | 13.12 | |
| 29. | Сәбәп хәле | Сәбәп хәле һәм аның белдерелүе.Укытучы аңлатуы, китап белән эш, тыңлау, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль | 17.12 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | күнегүләр эшләү | | |
| 30. | **Сочинение** | Язып бетерергә | 20.12 | |
| 31. | Хаталар өстендә эш. Максат хәле | Максат хәленең инфинитив фигыльләр, юнәлеш килешендәге исем, шулай ук өчен яки дип ярдәмлек сүзләре белән килгән башка сүз төркемнәре ярдәмендә белдерелүе.Укытучы аңлатуы, китап белән эш, тыңлау, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү | 24.12 | |
| 32. | Максат хәле | Максат хәленең инфинитив фигыльләр, юнәлеш килешендәге исем, шулай ук өчен яки дип ярдәмлек сүзләре белән килгән башка сүз төркемнәре ярдәмендә белдерелүе. | 10.01 | |
| 33. | Максат хәле. Күнегүләр эшләү | Укытучы аңлатуы, китап белән эш, тыңлау, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү | 14.01 | |
| 34. | Шарт хәле | Шарт хәле һәм аның белдерелүе.Укытучы аңлатуы, китап белән эш, тыңлау, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү | 17.01 | |
| 35. | Кире хәл | Кире хәл һәм аның белдерелүе.Укытучы аңлатуы, китап белән эш, тыңлау, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү | 21.01 | |
| 36. | Хәлләрнең аерымлануы һәм алар янында тыныш билгеләре | Укучыларның эзлекле фикер йөртә белү сәләтләрен тикшерү. Бирелгән тема буенча фикер алышу, сөйләп карау, караламага һәм чистага күчерү. | 24.01 | |
| 37. | Хәлләрнең аерымлануы һәм алар янында тыныш билгеләре | Аерымланган төрле хәлләрнең җөмләдә төрле урында килүе белән таныштыру.Логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә | 28.01 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | ясау. Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, күнегү эшләү. | | |
| 38. | **Изложение** | Укучыларның эзлекле фикер йөртә белү сәләтләрен тикшерү. Бирелгән тема буенча фикер алышу, сөйләп карау, караламага һәм чистага күчерү. | 31.01 | |
| 39. | Җөмләдә сүз тәртибе турында гомуми мәгълүмат | Татар телендә җөмлә кисәкләренең урнашу тәртибе, аның рус телендәге сүзләрнең урнашу тәртибеннән аермалы яклары. | 4.02 | |
| 40. | Җөмләдәге сүзләрнең уңай һәм кире тәртибе. | | 7.02 | |
| 41. | Татар һәм рус телләрендә җөмләдә сүзләрнең урнашу тәртибе | | 11.02 | |
| 42. | Гади җөмлә турында үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү. | Гади җөмлә турында башлангычта үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү. | 14.02 | |
| 43. | Гади җөмлә. Күнегүләр эшләү | Күнегүләр эшләү | 18.02 | |
| 44. | Әйтү максаты буенча җөмлә төрләре. Хикәя җөмлә. | Хикәя җөмләләрне өйрәнү, сөйләмдә, язуда дөрес куллану. | 21.02 | |
| 45. | Сорау җөмлә | Сорау җөмләләрне өйрәнү, сөйләмдә, язуда дөрес куллану | 25.02 | |
| 46. | Боеру җөмлә | Боеру җөмләләрне өйрәнү, сөйләмдә, язуда дөрес куллану | 28.02 | |
| 47. | Тойгылы җөмләләр | Тойгылы җөмләләрне өйрәнү, сөйләмдә, язуда дөрес куллану | 4.03 | |
| 48. | Әйтү максаты буенча җөмлә төрләре. Алар янында тыныш | Әйтү максаты буенча җөмлә төрләрен кабатлау. Алар янында тыныш | 7.03 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | билгеләре. | билгеләрен өйрәнү. | | |
| 49. | Җыйнак һәм җәенке җөмләләр | Җыйнак һәм җәенке җөмләләрне тирәнтен өйрәнү. Күнегүләр эшләү | 11.03 | |
| 50. | Эндәш сүзләр һәм алар янында тыныш билгеләре | Эндәш сүзләр һәм алар янындагы тыныш билгеләре турында мәгълүмат бирү.Укытучы аңлатуы, китап белән эш, тыңлау, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү | 14.03 | |
| 51. | Кереш сүзләр һәм алар янында тыныш билгеләре | Кереш сүзләрне җөмлә эченнән таба белү. Кереш сүзләрне сөйләмдә куллана белү. Алар янында тыныш билгеләрен дөрес куллана белү. | 18.03 | |
| 52. | **Изложение** | | 21.03 | |
| 53. | Эндәш сүз һәм кереш сүзләрне кабатлау | Эндәш сүзләр һәм алар янындагы тыныш билгеләре турында мәгълүмат бирү.Укытучы аңлатуы, китап белән эш, тыңлау, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү | 1.04 | |
| 54. | Эндәш һәм кереш сүзләрнең сөйләмдә куллану үзенчәлекләре | Кереш, эндәш сүзләрнесөйләмдә куллана белү. Кереш җөмләләрнең күбрәк җөмлә уртасында килүләре; аларның өтер, сызык, җәяләр беләдән аерылып күрсәтелүен белү. | 4.04 | |
| 55. | Эндәш һәм кереш сүзләр янында тыныш билгеләре | Кереш җөмләләрнең күбрәк җөмлә уртасында килүләре; аларның | 8.04 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | өтер, сызык, җәяләр беләдән аерылып күрсәтелүен белү. | | |
| 56. | Раслау һәм инкяр җөмләләр. | Раслау һәм инкяр җөмләләр турында мәгълүмат бирү. | 11.04 | |
| 57. | Раслау һәм инкяр җөмләләрнең сөйләмдә кулланылышы. | Раслау һәм инкяр җөмләләрнең сөйләмдә дөрес кулланылышы. | 15.04 | |
| 58. | Раслау һәм инкяр җөмләләрнең сөйләмдә кулланылышы | | 18.04 | |
| 59. | Сөйләм үстерү дәресе | Диалогик һәм монологик сөйләм формаларына ия булу. | 22.04 | |
| 60. | Текст | Текст өстендә эшләү: аңа исем бирү, планын төзү | 25.04 | |
| 61. | Бәйләнешле сөйләм үстерү дәресе | Диалогик һәм монологик сөйләм формаларына ия булу. Үз фикереңне белдерү һәм аны дәлилләү | 29.04 | |
| 62. | Күнегүләр өстендә эш | Күнегүләр өстендә эш | 2.05 | |
| 63. | **Сочинение** “Югалту җиңел түгел ул...” | Сочинение “Югалту җиңел түгел ул...” | 6.05 | |
| 64. | Әхлак кагыйдәләре турында сөйләшү | Әхлак кагыйдәләре турында сөйләшү | 9.05 | |
| 65. | Бәйләнешле сөйләм үстерү дәресе | Бәйләнешле сөйләм үстерү дәресе | 13.05 | |
| 66. | Бәйләнешле сөйләм үстерү дәресе | Бәйләнешле сөйләм үстерү дәресе | 16.05 | |
| 67. | **Диктант.** | Диктант. | 20.05 | |
| 68. | Хаталар өстендә эш | Хаталар өстендә эш | 23.05 | |
| 69. | Йомгаклапкабатлау | Йомгаклапкабатлау | 27.05 | |
| 70. | Йомгаклапкабатлау | Йомгаклапкабатлау | 30.05 | |